ГЛАВА
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.06.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 117**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы составына кертү өчен кандидатуралар тәкъдим итү турында

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2014 елның 21 февралендәге 363 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының гамәлдәге Иҗтимагый советы әгъзаларының вәкаләтләре вакыты тәмамлануга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советының яңа составын формалаштыру инициативасы белән чыгарга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы составына кертү өчен кандидатуралар тәкъдим итү вакыты - әлеге карар басылып чыккан көннән 30 көн эчендә;

2.2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Иҗтимагый советы турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә. Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты, 315 нче кабинет яисә Denis.Anisimov@tatar.ru электрон почта адресы буенча тәкъдимнәр тапшырылырга мөмкин.

3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**А.В. Тыгин**